РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
КИЛЬДЮШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛДЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 52-2-66, факс 52-2-66

# КАРАР

**22 ноябрь 2019 ел** **№ 1**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Килдеш авыл җирлегенең Килдеш торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Килдеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсенә нигезләнеп, **КАРАР БИРӘМ:**

2019 елның 5 декабрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Тәтеш районы Килдеш авылы Мәдәният йортында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең Килдеш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены оештырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Килдеш авыл җирлегенең Килдеш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, күпбалалы гаиләләр, I группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, локаль хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара

салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Килдеш авылы эчендәге юлларны төзекләндерү;
- Килдеш авылында чишмәне төзекләндерү;
- Килдеш авылы зираты коймасын төзекләндерү;
- Килдеш авылында урамнарны яктырту өчен лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;
- Килдеш авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Килдеш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Килдеш авыл җирлеге башлыгы** **В.С. Исаев**